# Балачагым

Әти-әни, абый-апа
Бар да якын, бар да янда
Яратуны тоеп үсү
Иң зур бәхет бу дөньяда

Бала бала бала балачак
Бер уйларсыз рәхәт матур чак
Иң күңелле,бәхетле вакытлар
Мәңгелеккә истә калачак...

Әби-бабай мактап тора
Иңнәремә канат куя
Аларның зур тәрбиясе
Һәр кешегә ярап куя

Балачагым диеп җырлыйм
Яшәүгә сөенеп туймыйм
Җиргә туган һәр баланың
Матур үтсен балачагы